**2026 ел - халыклар бердәмлеге, хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы**

Килешенде ________________
Әтнә районы Башкарма
комитетының "Мәгариф бүлеге"
казна учреждениесе җитәкчесе
Р.Р.Фатыхов

Раслыйм: ________________
Әтнә районы "Мәктәптән тыш
эшләр үзәге" өстәмә белем бирү
учреждениесе директоры
М.Н. Гарипова

**Татар шагыйре, Советлар Союзы Герое һәм Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулуга багышланган**
**"ҖЫРЛАП ҮТТЕМ ДАНЛЫ КӨРӘШ КЫРЫН..."**
**иҗади эшләр район конкурсы**

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**1.Төп нигезләмә**

1.1. Иҗади эшләр район конкурсы (Конкурс) Әтнә районы мәгариф бүлегенең планы нигезендә һәм "Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы", Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстанда башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан, Татар шагыйре, Советлар Союзы Герое һәм Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулуга багышлап эшләнә. Нигезләмә Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртипләрен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручылар – Әтнә районы мәгариф бүлеге, Әтнә районы "Мәктәптән тыш эшләр үзәге" өстәмә белем бирү учреждениесе,

**2. Конкурсның максаты һәм бурычлары**

2.1. Максат: Муса Җәлилнең әдәби мирасын, батырлыгын популярлаштыру

2.2. Бурычлар:

- әдәбият һәм сәнгатькә сәләте булган укучыларны ачыклау, аларга иҗади яктан үсүдә һәм камилләшүдә ярдәм күрсәтү;
- эстетик зәвык һәм әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;
- укучыларга туган җиребезнең фидакарь хезмәт һәм хәрби батырлары турында күбрәк мәгълүмат тупларга булышу;
-**Муса Җәлилнең** әдәби мирасын популярлаштыру, фронтовик язучылар иҗатына кызыксыну уяту ;
- укучыларның игътибарын рухи мирасыбызны өйрәнүгә юнәлтү.

**3. Конкурсның катнашучылары**

3.1. Конкурста, эш юнәлешләренә карап, районның гомуми һәм өстәмә белем бирү учреждениеләреннән 7 яшьтән 18 яшькә кадәр булган укучы балалар һәм укытучылар, педагоглар катнаша ала.

3.2. Конкурс түбәндәге яшь төркемнәре арасында үткәрелә:

- 7-10 яшьлек укучылар;
- 11-13 яшьлек укучылар;
- 14-18 яшьлек укучылар;

-укытучылар, өстәмә белем бирү педагоглары.

**4. Конкурсның эш юнәлешләре**

4.1. Конкурс түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

1) "Җирдә кеше торса торсын,
Эзе калсын тирән булып,
Үзе үлсә, эше калсын
Мең яшәрлек имән булып" - **14-18 яшьлек укучылар өчен**, Татарстанда хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы уңаеннан, төрле өлкәләрдә хезмәт һәм хәрби батырлык үрнәге булган районыбыз кешеләре турында **фәнни-эзләнү эшләре**;
2) "Үлемне җиңгән җырлар"- **11-13 яшьлек укучылар өчен, шигырь һәм проза әсәрләре (иншалар)**;
3) "Җырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!"- **7-10 яшьлек укучылар өчен**, Муса Җәлил шигырьләре буенча **рәсемнәр**;
4) "Сынаулары аша сыный тормыш,
Җиз иләктән кат-кат үткәрә"- **укытучылар өчен**, батырлык **дәресе һәм дәрестән тыш чара эшкәртмәләре.**

**5. Конкурсның үткәрелү вакыты һәм куелган таләпләр**

Конкурс эшләрен түбәндәге таләпләр буенча 2026 елның 28 гыйнвареннән башлап 14 февральгә кадәр мәгариф бүлегенә тапшырырга (Садриева Рита Ришатовнага).

- **Фәнни-эзләнү эшләре** А4 форматта (шрифт 14, Times New Roman, юлара интервал –одинарный. Як-яктан кырлар – 2-1.5 см., өстән - 2см, астан - 2 см. киңлектә калдырырга). Кулланылган әдәбият исемлеге текст азагында алфавит тәртибендә бирелә. Эшнең күләме 3 биттән ким булмаска һәм 10 биттән артмаска тиеш;

- **шигъри язмалар** кәгазь битенең сул ягы буенча тигезләнә.;

- **чәчмә әсәрләр** кәгазь битенең киңлеге буенча тигезләнә;

- язманың исеме уртада ярымкалын шрифт белән күрсәтелә;

- язма ахырында авторның тулы исеме, фамилиясе, укыган мәктәбе, сыйныфы, тулы яше, язма эшне башкарырга булышкан җитәкченең (әгәр

булса. Укучы эшне үзе генә дә башкарырга мөмкин) Фамилия һәм инициаллары языла.

- **рәсемнәр** А3, А4, А5 форматта булырга мөмкин. Як-якта буш кырлар калдыру мәҗбүри түгел. Техникасы – ирекле (карандаш, гуашь, акварель...). Рәсемнең аскы ягына таблица формасын тутырып ябыштырырга (шрифт 12, Times New Roman, юлара интервал –одинарный)

| | |
|---|---|
| Исеме | “Минем әбием –тыл батыры” |
| Автор | Галиева Гөлия |
| Тулы яше | 10 яшь |
| Мәктәбе, сыйныфы | Әтнә районы Күәм урта мәктәбе 4сыйныф |
| Җитәкчесе | Валиева А.Б. |

-**дәрес һәм дәрестән тыш чара эшкәртмәләре** А4 форматта (шрифт 14, Times New Roman, юлара интервал –одинарный. Як-яктан кырлар – 2-1.5 см., өстән - 2см, астан - 2 см. киңлектә калдырырга), титул бите белән тапшырыла. Титул битенә белем бирү оешмасының тулы исеме, эшкәртмә материалның темасы һәм тулы итеп укытучынын фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

**6. Конкурс эшләрен тикшергәндә игътибар ителә торган критерийлар:**

- Конкурс эшләре моңарчы башка матбугатта басылмаган, башкалардан күчерелмәгән булырга тиеш;
- Эшләрнең оригинальлегенә өстенлек бирелә;
- Эшләр хатасыз, куелган таләпләргә туры килгән булырга тиеш;
- Теманың ачылышына, тарихи фактларга, эзләнүләргә бай булуына өстенлек бирелә;
- Эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр булу, фото фактлар белән баетып бирү хуплана);
- Рәсемнәрнең укучы бала кулы белән ясалганына өстенлек биреләчәк.

**7. Конкурска нәтиҗәләр һәм жюри**

Конкурс эшләрен Әтнә районы “Мәктәптән тыш эшләр үзәге” оешмасы “Журналистика” берләшмәсе җитәкчесе җыя.

Эшләргә нәтиҗә 2026 елның 15 февраль числосында ясалачак. Һәр эш юнәлешендә 1,2,3 урыннар билгеләнә. Аларга Җиңүче дипломнары һәм барлык катнашучыларга Катнашучы сертификаты биреләчәк.

Белешмәләр өчен элемтә: Тел. 89520361781 - Садриева Рита Ришатовна